ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КРАСНОСЛОБОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
СПАССКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

№ 14 от 10.06.2020 г.

Об утверждении порядка опубликования ежеквартальных сведений о численности муниципальных служащих органов местного самоуправления Краснослободского сельского поселения Спасского муниципального района РТ и фактических расходах на оплату их труда

В соответствии с частью 6 статьи 52 Федерального закона от 6 октября 2003 года N 131-ФЗ "Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации", Уставом муниципального образования Краснослободского сельского поселения Исполнительный комитет Краснослободского сельского поселения Спасского муниципального района Республики Татарстан

ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Утвердить Порядок опубликования ежеквартальных сведений о численности муниципальных служащих органов местного самоуправления Краснослободского сельского поселения и фактических расходов на оплату их труда (прилагается).

2. Опубликовать настоящее постановление на официальном сайте Спасского муниципального района (http://www.spasskiy.tatarstan.ru), на официальном сайте правовой информации (//http:pravo.tatarstan.ru).

3. Контроль за исполнением настоящего постановления оставляю за собой.

Руководитель исполнительного комитета
Краснослободского сельского поселения А.В. Алиев.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Кызыл Бистә
авыл җирлеге башкарма комитеты карарына 1 нче кушымта
2020 елның 10 июненнән № 14

## Кызыл Бистә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен белешмәләр бастырып чыгару тәртибе

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1 Кызыл Бистә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнар турында квартал саен бирелә торган белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе (алга таба - Тәртип) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Кызыл Бистә авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән.

1.2. Тәртип Кызыл Бистә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә фактик чыгымнар турында квартал саен бирелә торган мәгълүматларны (алга таба - белешмәләр) тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели.

### II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында белешмәләрне тапшыру һәм аларның составы

2.1. Белешмәләр квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача исемлек саны турында, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыручы Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына карата түләүләрне исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын гамәлгә ашыруга фактта җибәрелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен (акчалата тотуны) чагылдыра.

2.2. Белешмәләр хисап чорыннан соң килә торган айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипкә кушымта нигезендәге рәвеш буенча тапшырыла.

2.3 Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

### III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләрне бастырып чыгару тәртибе

3.1. Кызыл Бистә авыл җирлегенең башкарма комитеты хисап чорыннан соң килүче айның соңгы санынннан да соңга калмыйча Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитетының белешмәләрне раслау турындагы карары проектын әзерли.

3.2 Кызыл Бистә авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр хисаптан соң килүче икенче айның соңгы санына кадәр Кызыл Бистә авыл җирлеге сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәрләре
саны һәм аларның хезмәте өчен түләүгә факттагы
чыгымнар турында квартал саен бирелә торган
белешмәләрне бастырып чыгару тәртибенә кушымта

Кызыл Бистә авыл җирлегенең җирле үзидарә органнары муниципаль хезмәткәрләренең саны һәм аларның хезмәте өчен хисап чорының________________20___елгы түләүгә факттагы чыгымнар турындагы белешмәләр (беренче квартал, яртыеллык, тугыз ай, бер ел)

| Хезмәткәрләр категориясе | Хисап чорында хезмәткәрләрнең уртача исемлек саны, кеше | Хисап чорында хезмәткәрләргә хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар, мең сум |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Кызыл Бистә авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |